ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

11.10.2022 — пос. Октябрьский — 03

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2022 елның 23 октябренә билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрү белән сез килешәсезме:

   - Яңа Болгар авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау

   - Зират территориясен төзекләндерү

   - Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү өчен төзелеш материалы алу

   «ӘЙЕ» «ЮК»
3. Яңа Болгар авыл клубы бинасында халык җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Яңа Болгар авылы, Мәктәп урамы, 42 йорт 10.00 сәгатьтә.
4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов